| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2020

№ 1255

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017 - 2020 елларга Алабуга муниципаль районында мәгарифне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 17 ноябрендәге 1441 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә һәм Алабуга муниципаль районында мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017 - 2020 елларга Алабуга муниципаль районында мәгарифне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 17 ноябрендәге 1441 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендәге «2017-2020 еллар» сүзләрен «2017-2023 еллар» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. «2017 - 2023 елларга Алабуга муниципаль районында мәгарифне үстерү» муниципаль программасын кушымта итеп бирелгән яңа редакциядә расларга (Кушымта).

2. «Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә (Э.И. Садыйкова) муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыру өчен бюджет ассигнованиеләрен күздә тотуны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар рәсми төстә бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов